# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Беловка авыл җирлегенең Беловка авылы
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы

2019 елның 22 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 1131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Беловка авылында гражданнар җыены

Карар итте:

1.2020 елда Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге Беловка территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

Беловка авыл җирлеге Беловка авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

- Беловка авылы урамнарына агымдагы ремонт (грунтны күтәрү-вак таш җәю)
- вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Беловка авылында урамнарны кышкы карап тоту

2.Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ